**Әдәбият**

1. Әхмәдгалиева А. Синең өчен яшим: повесть, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 207 б.
2. Габделхакова Р. Кышлары салкын булса да... // Казан утлары. – 2019. – №3. – Б. 149-153.
3. Гыйльманов Г.Х. Тәкъдиргә юл: хикәяләр, новеллалар. – Казан: Рухият, 2014. – 448 б.
4. Закирҗанов Ә.М. Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 287 б.

УДК 398

# ТРАДИЦИИ ФАТИХА УРМАНЧЕЕВА В ТАТАРСКОМ ЭПОСОВЕДЕНИИ
# ТАТАР ЭПОС БЕЛЕМЕНДӘ ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

**Фазлутдинов Ильназ Ильдусович**
*Институт социально-философских наук и массовых коммуникаций*
*Казанского (Приволжского) федерального университета,*
*г. Казань, Татарстан, Российская Федерация*
*e-mail: fazl97@mail.ru*
**Закирова Ильсеяр Гамиловна**
*Институт языка, литературы и искусства им.*
*Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан,*
*г. Казань, Татарстан, Российская Федерация*
*e-mail: ilzakirova@mail.ru*

***Аннотация.*** *В данной статье авторы рассматривают деятельность известного ученого, доктора филологических наук, профессора, заслуженного деятеля науки Республики Татарстан Фатиха Ибрагимовича Урманчеева. Актуальность данной работы обусловлена не только глубоким вкладом ученого в формирование и развитие татарской эпосоведческой школы, но определяется и обширной деятельностью Ф.И. Урманчеева в качестве преподавателя и проректора Елабужского педагогического института (ныне Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета), а также тем, что имя выдающегося фольклориста до сих пор не увековечено в названном городе и его учебных заведениях, в частности, в академическом плане. Авторы статьи предпринимают попытку провести обзор ценнейших научных трудов Ф.И. Урманчеева, давно ставших библиографической редкостью; инициируют организацию на базе ЕИ КФУ или иных образовательных учреждений г. Елабуги научно-практической конференции «Урманчеевские чтения», которая могла бы послужить примером глубокого уважения ученому и почитания заложенных им академических традиций, а также данью памяти учеников своему учителю. Статья предназначена для филологов, культурологов, историков и всех тех, кто интересуется духовной культурой татар.*

***Ключевые слова****: фольклористика, татарский эпос, Урманчеев, дастан, Идегей, Елабуга, чтения, фольклорист, преподаватель, духовная культура татар.*

# TRADITIONS OF FATIKH URMANCHEEV IN TATAR EPIC STUDIES

**Fazlutdinov Ilnaz Ildusovich**
*Institute of social and philosophical studies and mass media of the Kazan (Volga region) federal university, Kazan, Tatarstan, Russia*
**Zakirova Ilseyar Gamilovna**
*G. Ibragimov Institute of language, literature and art of Tatarstan Academy of Sciences, Kazan, Tatarstan, Russia*

***Abstract****. In this article, the authors examine the activities of the famous scientist, Doctor of Philology, professor, Honored Scientist of the Republic of Tatarstan Fatikh Ibragimovich Urmancheev. The relevance of this work is due not only to the deep contribution of the scientist to the formation and development of the Tatar school of epic studies, but is also determined by the extensive activities of F.I. Urmancheev as a teacher and vice-rector of the Elabuga Pedagogical Institute (now the Elabuga Institute of the Kazan (Volga) Federal University), and also by the fact that the name of the outstanding folklorist has not yet been immortalized in the named city and its educational institutions, in particular, in academic terms. The authors of the article attempt to review the most valuable scientific works of F.I. Urmancheev, which have long become a bibliographic rarity; initiate the organization on the basis of the EI KFU or other educational institutions in Elabuga of a scientific and practical conference «Urmancheev»s Readings», which could serve as an example of deep respect for the scientist and veneration of the academic traditions he laid down, as well as a tribute to the memory of the students to their teacher. The article is intended for philologists, culturologists, historians and all those who are interested in the spiritual culture of the Tatars.*

***Keywords:*** *folkloristics, Tatar epos, Urmancheev, dastan, Idegei, Elabuga, readings, folklorist, teacher, spiritual culture of the Tatars.*

Татар эпосын өйрәнү турыдан туры олуг галим Ф.И. Урманче исеме белән бәйле. Аның эшчәнлеге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтындагы халык иҗаты бүлегенең фәнни юнәлешләре формалашуында да гаять зур роль уйнаган. Шуларның иң әһәмиятлесе – нәкъ Ф.И. Урманчеев җитәкчелегендә халык эпосын фәнни тикшерүнең төп проблемалары билгеләнүе.

Татар фольклористикасында халык эпосын өйрәнү, ярты гасырга тукталып торганнан соң, бары тик узган гасырның 80 елларында гына Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре тарафыннан яңадан башланып китә. Ф.И. Урманчеевнең 1984 елда басылып чыкан «Татар халкының героик эпосы» монографиясе шушы эшчәнлекнең беренче нәтиҗәсе була. Әмма, ВКП(б) Үзәк Комитетының әсәрне өйрәнүне тыйган 1944 елның август карарына бәйле рәвештә, әлеге китапка ««Идегәй» дастаны» дип исемләнгән бүлек кертелми. Шуңа да галимнең «Татар халкының героик эпосы» монографиясендә аерым урын алып торырга тиешле «Идегәй» дастанына багышланган хезмәте беренче мөмкинлек туу белән соңрак кына – бары тик 1999 елда – аерым китап булып чыга. Шулай итеп, чор сәясәте нәтиҗәсендә бер монографиядә янәшә килергә тиешле тикшеренүләр аерым нәшер ителә [7, б. 4].

Татар һәм, гомумән алганда, төрки халыкларының эпик иҗатын өйрәнү халык иҗаты бүлегенең әһәмиятле юнәлешен били. Фольклористлар Ф.И. Урманчеев эшен тиешенчә дәвам итәләр. Халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләре татар дастаннарын өйрәнү эшен берничә аспекттан чыгып башкара. Дастаннар турындагы монографияләр һәм байтак кына теоретик мәкаләләр, махсуслашкан тикшеренүләр даими нәшер ителә. Биредә Ф.И. Урманчеевның «Татар героик эпосы» монографиясеннән тыш (Казан, 2015), аның шәкертләре хезмәтләрен – И.Г. Закированың «Алтын Урда чоры эпик иҗаты»н (Казан, 2011), Л.Х. Мөхәммәтҗанованың

«Татар эпосы: китаби дастаннар»ын (Казан, 2014), «Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары»н (Казан, 2018) аерым билгеләп үтәргә мөмкин. 2019 елда рус телендә «Татар халык иҗаты. Дастаннар» җыентыгы дөнья күрде. «Татар халык иҗаты» яңа 25 томлык академик тупланмасында татар эпосына IX һәм X томнар багышланган (Казан, 2023). Аларның беренчесендә классик (телдән башкарыла торган) дастаннарга урын бирелсә, икенчесе инде бары тик китаби (ягъни язма рәвештә генә сакланган) дастаннарга багышлана.

Халык эпосын популярлаштыруга бәйле зур эш алып барыла. Дастаннар текстлары фольклор җыентыкларында басылып чыга, шул ук вакытта аерым текстлар вакытлы матбугатта дөнья күрә башлады.

Халык эпосына карата игътибар артуын бүлек хезмәткәрләре әзерләгән һәм соңгы елларда басылып чыккан күпсанлы монографияләр, теоретик мәкаләләр җыентыклары гына түгел, ә шул ук вакытта хәзерге фольклористиканың актуаль мәсьәләләренә багышланган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре дә күрсәтеп тора. Ф.И. Урманчеев җитәкчелеге астында эшләгән еллар дәвамында эпосны өйрәнүнең актуаль мәсьәләләренә, жанр төрлелегенә һәм дастаннар классификациясенә, сюжет үзенчәлекләре һәм образлар системасына, тарихи һәм мифологик нигезләрне тикшерүгә багышланган дистәләгән кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклanган, күпсанлы профильле белгечләр әзерләнгән. Соңгы елларда халык иҗаты бүлегенең ике хезмәткәре татар дастаннарын тикшерүне максат итеп торкан докторлык диссертацияләрен яклады. Әлеге диссертацияләр өчен теманы билгеләүдә төп өлеш тә нәкъ Ф.И. Урманчеевка кайтып кала. И.Г. Закирова үз диссертациясендә татар дастаннарының тарихи нигезләрен һәм мифопоэтик традицияләрен тикшерә, Л.Х. Мөхәммәтҗанова китаби дастаннарны татар халкы эпик мирасының аерым бер өлеше буларак карый һәм аларның жанр үзенчәлекләрен анализлый.

Исеме бөек эпос белгечләре, халык иҗатын тикшерүчеләр В.М. Жирмунский, Е.М. Мелетинский, В.Я. Пропп исемнәре белән беррәттән яңгыраган Ф.И. Урманчеевның эшчәнлеге таныштыруга мохтаҗ түгел. Ф.И. Урманчеевның фәнни тикшеренүләре төрки, аерым алганда татар фольклористикасының үсеш перспективасын билгеләү белән чикләнмичә, фәнни фикер үсешен дистә елларга узып бара. Аның гомумтөрки эпосы буенча хезмәтләре фольклор мирасын тикшерүгә зур өлеш кертә.

Ф.И. Урманчеев үзенең тормыш юлын автобиографиясендә яктырта. Булачак галим 1936 елның 28 маенда Омск өлкәсенең Кызыл Маяк авылында Фәхретдин улы Ибраһим һәм Сөләйман кызы Срурнисә гаиләсендә туа. Ләкин гаиләдәге бердәнбер малай тууга 6 ай кала аның атасы Колымага сөргенгә җибәрелә. 36 яшьлек әнисе биш бала белән берүзе кала. «1941 елда Бөек Ватан сугышы башлангач, әниебез бары тик биш баласын ач үлемнән ничек коткаруы турында уйлый иде» - дип үз балачагы турында ачынып сөйли торган була Ф.И. Урманчеев [9, б. 6]. Дөнья игелекле кешеләрсез түгел: колхоз рәисе, гаиләнең котылгысыз хәлен күреп, Срурнисә апага тракторчылар бригадасында ашарга пешерүче эшен тәкъдим итә. Бакча һәм шушы хезмәт урыны аркасында балалар ач үлемнән коткарылган була. Колхоз рәисе булып Шарыкбай ага дигән кеше эшләгән, аны Фатих Ибраһим улы гомере буе аерым бер җылылык һәм рәхмәт хисе белән искә алган.

1944 елда, Фатих Урманчеев мәктәп яшенә җиткәч, аның рус мәктәбендә сигезъеллык белем алган бертуган апасы 18 яшьлек Мәсфия туган авылларында башлангыч мәктәп ачып җибәрә һәм белем бирүне туган телләре – татар телендә алып бара башлый. Шушы туташ аркасында мәктәп яшенә җиткән барлык балалар башлангыч белем алу мөмкинлегенә ия була. Моңарчы, русча аралаша алмаган бала-чаганың нинди дә булса белем алу мөмкинлеге бөтенләй булмаган. Янәшәдәге авылларның рус һәм нимес мәктәпләренә урнашу омтылышлары да уңышсызлыкка дучар була, чөнки бер рус сүзен белмичә рус мәктәбендә уку мөмкин булмый.

Мәктәптәге бөтен дәресләр туган телдә алып барыла. Гомере буена йөзләгән грамота, мактау хатлары белән бүләкләнгән Фатих Ибраһим улы башлангыч мәктәпне уңышлы тәмамлавы турындагы үзенең беренче грамотасын гомере буе хәтерләгән һәм еш кына истәлекләрендә телгә алган. Башлангыч мәктәпне бетергәч укуны дәвам итү мәсьәләсе килеп

баса. Ярдәм кулын күрше Тарбак авылының Киров җидееллык казах мәктәбе укытучысы Даркен ага суза. Кызыл Маяк балалары укуларын казах мәктәбендә дәвам итә, монда алар туган телләренә якынрак, шуңа курку хисе уятмаган һәм белем алуда җиңеп чыга алмаслык киртә тудырмаган казах телендә генә түгел, ә русча да аралашырга һәм язарга өйрәнәләр.

Халык иҗатына карата үзенең аерым мөнәсәбәтен Ф.И. Урманчеев балачак хатирәләре белән аңлаткан. Фатих абыйның әнисе Срурнисә апа, ул дәвердәге татар хатын-кызларының күпчелеге кебек үк, һәрвакыт ишетелер-ишетелмәс кенә мөнәҗәтләр һәм бәетләр укыган, боларның сагышлы-моң-зарлы көйләре малай күңелен тетрәндереп, аның исенә гомерлеккә кереп калган. Шуңа да, Ф.И. Урманчеевнең 1974 елда басылып чыккан «Халык авазы. Татар халык бәетләре тарихыннан очерклар» дип исемләнгән беренче монографиясе темасының да бәетләр белән бәйле булуы очраклы түгел.

Алай да Фатих Урманчеевнең иң «беренче» китабы да була, аны малай 14 яшендә «бастырырга» була: төзүчесе Ф. Урманчеев, Кызыл Маяк, 1950 ел. Күләме 5 п.б. Тираж – 1 экз. Шушы чын, җитди хезмәткә тиешле булганча, каты тышлыктагы китапны Фатих абый гомере буе кадерләп саклый [9, б. 7].

Җидееллыкны тәмамлагач Фатих Урманчеев Омск шәһәренә Казах педагогика училищесенә укырга керә. Аны тәмамлап Омск дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетына барып урнаша. Монда «Халык поэтик иҗаты» түгәрәге эшләп килә. Нәкъ менә шушы түгәрәктә катнашу Ф. Урманчеев өчен фольклористиканың күпкырлы дөньясын ачкан юлның башы була. Түгәрәкнең актив әгъзасы һәм старостасы буларак, ул «Татар халык җырлары», «Татар халык бәетләре» дигән чыгышлар ясый, үз чыгышларын пластинкаларга кушылып алып бара.

Түгәрәк җитәкчесе В.А. Василенко үзенең «Рус фольклоры» күптомылыгының V томында чыккан «Фольклорчылар түгәрәгенең эш тәҗрибәсе» мәкаләсендә болай дип яза: «V курс студенты Ф.И. Урманчеев инде өч ел «Омск өлкәсендәге татар халык җырлары» (үз язмалары буенча) темасы өстендә эшли. Аның теоретик эше җыю белән үрелеп бара, шуңа зур кызыксыну уята» [2, б. 462]. Әлеге мәкаләне укып чыккач, И.Н. Надиров, ул елларда Тел, әдәбият һәм тарих институтының директор урынбасары, һәм фольклор секторы хезмәткәре Э. Касыймов Ф. Урманчеевны рәсми хат белән аспирантурага чакыралар.

1967 елда Ф.И. Урманчеев «Татар совет халык-поэтик иҗатының төп жанрлары үсеше юллары» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. Кандидатлык диссертациясен яклаганнан соң Фатих Ибраһим улы язмышының шактый зур өлешен, төгәлрәге 22 елын, студентларны өйрәтүгә багышлый: берничә ел Казан педагогика институтында ассистент вазыйфаларын үти, ун ел Алабуга педагогика институтында проректор булып эшли, дүрт ел Венгриядә Эгер шәһәрендә студентларга рус әдәбияты буенча белем бирә, чит ил командировкасыннан соң Алабуга techинститутына рус әдәбиятын укытырга кайта.

Күп еллар дәвамында галим эшчәнлеге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән бәйле булмавына карамастан, Ф.И. Урманчеев фольклористикадан читкә китми. Фольклорны үз рухи дөньясының төп кыйммәте итеп санап, ул гомере буе төрле бәхәсле мәсьәләләрдә төшенергә тырышып, халык иҗатының жанрларын өйрәнүне дәвам итә.

Галимнең югары уку йортларында эшләгән дәверендә басылган монографияләрендә, фәнни журналлар һәм җыентыклардагы мәкаләләрендә халык иҗатының фундаменталь мәсьәләләре яктыртыла.

Ф.И. Урманчеев беренчеләрдән булып татар дастаннарын төрки халыкларның эпосы белән чагыштырма аспекттан чыгып системалы өйрәнүгә тотына. Узган гасырның 70-80 елларында «Совет тюркологиясе» журналында татар эпосын өйрәнүгә багышланган күпсанлы мәкаләләр дөнья күрә: «Ак Күбек» героик дастаны (1977, № 3); Төрки халыкларның «Йир Төшлек» дастаны (1978, № 1), «Ак бүре эзләреннән» (1978, № 6); Болгар батырлары турындагы легендалар һәм Алпамыш турындагы дастан (1980, № 2); «Җик Мәргән» дастанында төрки эпос традицияләре (1980, № 4); «Кузы Күрпәч белән Баян сылу» дастанының татар версиясе (1981, № 5); «Алтаин Саин Сүмә» героик-архаик дастаны (1984, № 2); Эпик герой исеме (1986, № 4); Байрактагы алтын бүре башы (1987, № 3); Татар

фольклорында баласызлык мотивы (1988, № 1) һ.б. Шулай итеп, галим фәнни дөньяга татар халкының үз эпосы – дастаннары – булуы хакында хәбәр итә һәм шуны дәлилли. Аның эшчәнлеге татар эпосын «ханнар, феодаллар эпосы» буларак бәяләгән 1944 елның 9 августыннан булган ВКП(б) Үзәк комитетының карарыннан соң татар эпосын фәнни тикшерүне яңадан башлап җибәрү була.

1980 елда Ф.И. Урманчеевның татар халкының эпик иҗатын өйрәнүгә багышланган «Татар халкының эпик дастаннары» монографик хезмәте басылып чыга.

1970 еллар ахырына таба Ф.И. Урманчеев «Татар халкының героик эпосы» темасына башкарылган докторлык диссертациясен тәмамлый һәм диссертация нигезендә әзерләнгән монографиясен Татарстан китап нәшриятына тапшыра. Беренче эш итеп бастырылырга тиешле китап нәшриятта берничә ел ята. Галимнең Венгриягә китүенә сәбәпле докторлык диссертациясенең яклавы да узмыйча кала. «Татар халкының героик эпосы» монографиясе бары тик 1984 елны фольклорчының чит илдән кайтуыннан соң гына басыла. 3300 данә тиражы белән чыккан китап бөтенсоюз киңлегендә генә түгел, ә чит илләрдә дә тиз таралып, югары бәяләмәләр җыя.

Гарчә ул вакытка татар эпосы буенча фәнни тикшеренүләр өчен байтак кына материал тупланган булса да, жанр барыбер татар фольклорының иң өйрәнелмәгән бер өлкәсе булып калып барган. Шуның белән бу монографиянең һәм гомумән галим эшчәнлегенең актуальлеге билгеләнә дә инде. Анализга татар фольклорын өйрәнүнең иң әһәмиятле чыганакларының берсе – В.В. Радловның «Образцы»ларының дүртенче китабы, шул ук вакытта тарихи чыганакларда урын алган материаллар, Казан шәһәрендәге революциягә кадәрге типографияләрдә чыккан, шулай ук журналлар битләрендә, фәнни язмаларда, хезмәтләрдә, хәбәрләрдә дөнья күргән күпсанлы дастаннар, һәм, әлбәттә, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгенең фольклор фондында (ул вакытта: СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Тел, әдәбият һәм тарих институтының Фольклор фонды) тупланган кульъязма материал тартыла. Ф.И. Урманчеев бу фондны тулыландыруга үзе зур өлеш кертә, анда бүгенге көнгә кадәр галим тарафыннан фольклор экспедицияләре барышында язып алынган бик күп текстлар саклнган.

Монография дүрт бүлектән тора. Беренче бүлектә автор халык эпосын җыю һәм өйрәнү тарихын, эпос белеменең гомум мәсьәләләрен карый. Киләсе өч бүлек татар эпик фольклорының жанр төрләренә – дастаннар, бәетләр һәм тарихи җырларга – багышланган була. Татар дастаннарына багышланган икенче бүлектә «Түләк», «Йир Төшлек», «Алтаин Саин Сүмә» героик-архаик дастаннары, «Алпамыш», «Ак Күбек», «Гайсә улы Әмәт», «Җик Мәргән», «Күр углы» героик дастаннары, «Кузы Көрпәч белән Баян Сылу» лироэпик дастаны, «Таһир белән Зөһрә» китаби дастаны анализлана. Ф.И. Урманчеев билгеләвенчә, үзләренең художество үзенчәлекләре буенча бу дастаннар төрле тарихи дәверләргә карый, шуңа бәйле рәвештә аларның эчтәлегендә теге яки бу мотив һәм образлар өстенлек итә. Татар эпосын тикшергәндә галим зур игътибарны аның төп сюжет линиясен торгызуга, образларны – эпик батыр, аның кәләше, батырның дошманын – тикшерүгә бирә.

«Татар халкының героик эпосы» монографиясендә галим киләчәктә уңышлы дәвам ителгән һәм төрки халыкларның эпосларын өйрәнүдә кулланыла торган эпик текстларны тикшерү моделен тәкъдим итә. Галимнең югары профессиональлеген, аның фәнни карашларының масштаблылыгын һәм белеменең киңлеген, нәтиҗәләренең әһәмиятлелеген һәм төплелеген билгеләмичә мөмкин түгел. Ф.И. Урманчеев тарафыннан дастаннарга карата тәкъдим ителгән анализ моделе һәр халыкның эпик иҗатын өйрәнү өчен эффектив булып тора, әлеге жанрның үзенчәлекләрен ачыклауда ярдәм итә, эпик әсәрләргә юнәлтелгән тарихи-типологик тикшеренүләр өчен перспективалар ача, тирән фәнни нәтиҗәләр һәм ачышларны тәэмин итә. Монографиядә шулай ук татар дастаннарын өйрәнүнең төп юнәлешләре һәм перспективалары билгеләнгән.

Галим шулай ук эпосның халыкның рухи тормышындагы функцияләрен, аның милли спецификасын, дастаннарның татар халкының тарихы һәм мәдәнияте белән бәйләнешен өйрәнә.

Ф.И. Урманчеев монографиясе күп еллар дәвамында дастаннар буенча бердәнбер тикшеренү булып кала һәм фәнни тикшеренүләр кысаларында гына түгел, ә студентларның мөстәкыйль белем алу барышында да кулланыла.

Ф.И. Урманчеев үзенең беренче докторлык диссертациясен гыйльми дөньяга монография рәвешендә тәкъдим итеп, бу эшне якламый, һәм кыска гына вакыт эчендә башка тема өстендәге эшен төгәлли – 1989 елда ул «Татар халык бәетләренең формалашуы һәм үсеше» темасына язылган докторлык диссертациясен яклый.

1991 елда Ф.И. Урманчеев Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты бүлеге мөдире итеп билгеләнә.

Шуны да аерым билгеләп үтү мөһим, нәкъ Ф.И. Урманчеев үзеннән башлап татар эпос белгечләре плеядасын ачып җибәрә, татар эпосоведларының һәммәсе дә аның укучылары яки укучыларының укучылары, аның хезмәтләрендә үсә һәм татар дастаннарын төрки дөньяның бердәм эпик мирасының бер өлеше буларак өйрәнүне дәвам итәләр.

1999 елда галимнең чираттагы хезмәте – «Халык эпосы «Идегәй»« монографисе басылып чыга. Бу дастанга багышланган беренче монография була. Автор дастанның милли татар версиясен чагыштырма-типологик һәм чагыштырма-тарихи аспектта тикшерә, башка халыклар иҗатыннан милли версияләрне җәлеп итә. Аерым билгеләп үтәргә кирәк, шушы монография, ВКП(б) Үзәк комитетының 1944 елгы билгеле карарларыннан соң ярты гасыр вакыт узуына карамастан, берничә ел үз сәгатен көтеп ята. Моны әлеге эшкә бирелгән һәм даталары 1995 елга караган бәяләмәләр раслап тора [4, б. 141-142]. Әйтеп үтелгән карарлар, билгеле булганча, рухи мирасның бик зур өлеше юкка чыгуына, талантлы галимнәрне эзәрлекләүгә һәм аларның архивларын юк итүгә китерә. Бу курку, башта тулысы белән нигезле һәм вакытлар узган саен уйланма, фантомга әйләнгән, ачы тәҗрибә белән килгән саклык тойгысы, татар эпос белемен озын-озак елларга тоткарлый.

Ф.И. Урманчеев үз хезмәтләрендә булган барлык басма һәм кульъязма материалларны җәлеп итә. Монографиядә Идегәй образы эпик һәм тарихи вакыйгалар фонында карала, Идегәйнең эшчәнлеге күренекле гаскәр башлыгы, дәүләт эшлеклесе һәм дипломат эшчәнлеге буларак бәяләнә. Ф.И. Урманчеев Идегәйнең фольклордагы образын эпик традицияләргә нигезләнеп тикшерә.

2015 елда Ф.И. Урманчеевның үзе исән чагындагы соңгы монографиясе – күпъеллык фәнни эшчәнлегенең ачык нәтиҗәсе һәм эпос белемендәге тикшеренүләренең йомгагы булган «Төрки героик эпосы» басылып чыга [19].

Монграфиядә төрки эпос сюжет композициясен төзегән төп мотивлар аша бербөтен система буларак анализлана. Галим төрки эпосны чагыштырма-тарихи планда тикшереп, аны бөтендөнья эпосының бер өлеше буларак карый. Кереш өлештә төрки халыкларның эпосын тикшерүгә багышланган хезмәтләргә күзәтү бирелә. Эшнең максаты – күпсанлы мотивлардан торган эпик әсәрнең композицион берлеген торгызу һәм реконструкцияләү; эпос композициясенең эзлекле система булганлыгын дәлилләү; халык эпосының «гомум» борынгы архетипик сюжетын табу.

Монография эпос структурасы белән тәңгәл килгән «Башлангычлар. Бәян итү башы», «Баласызлык. Балалы булуны үтенү», «Геройның тууы», «Эпик герой исеме», «Геройның балачагы. Батыр аты һәм корал», «Батырны яучылау», «Батырлар бәрелеше», «Геройларның үлеме. Бәян итү ахыры» кебек бүлекләрдән тора. Галим һәрбер мотивны фольклорның иң борынгы катламнарына үтеп, генетик тамырларын өйрәнеп, мифология, этнография, тарих фәннәренең мәгълүматлары белән чагыштырып тикшерә.

Галим хезмәтләрендә төрки эпосның генезис мәсьәләләренә, татар дастаннарының башка төрки халыкларның эпик мирасы белән бәйләнешләренә зур игътибар бирелә.

Ф.И. Урманчеев фольклористикада тиешле нәтиҗәләрне бары тик зороастризм, буддизм, христианство һәм ислам китапларында ук урнашкан борынгы көнчыгыш мифологиясенең, фольклорының һәм язма әдәбиятының традицияләрен исәпкә алып эпик әсәрләрнең сюжетын һәм композициясен, фольклорның һәм әдәби әсәрләрнең төп мотивларын, сюжет һәм композицион үзенчәлекләрен өйрәнү генә бирә, дип яза [19, б. 34]. Фатих Ибраһим улы эпоста тасвирланган традицияләрнең, вакыйгаларның, йолаларның, гомумән алганда төрки, һәм, аерым алганда, татар халыкларының рухи тормышында никадәр сакланып калганлыгын күзәтә.

Фатих Урманчеев татар халкының фольклор мирасын, шул исәптән татар дастаннарын, чит илләрдә популярлаштыру өчен күп көч салган. Ул 1991 елда Төркиядә басылып чыккан татар дастаннарының төрек телендәге җыентыгын төзи. Галим чит илләрдә узган күпсанлы фәнни симпозиумнарда катнаша, үз чыгышларында ул татар эпосын өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре белән таныштыра.

Ф.И. Урманчеевның фәнни кызыксынулары бары тик дастаннарны тикшерү белән чикләнми. Ул 15 монография, күпсанлы җыентыклар, 300дән артык фәнни мәкаләләр авторы, тагын 15 монография аның эшкәртүе яки катнашуы белән басылып чыга.

«Татар мифологиясе» 3 томлык энциклопедик сүзлегендә галим эпик образ һәм мотивларны, аларның генезисын, формалашуын һәм трансформациясен тикшерә.

Фатих Урманчеев төрки халыкларның фольклорын яхшы белә. Төрек, казах, азәрбайҗан галимнәре белән якын аралаша. Галим казахлар белән казахча, төрекләр белән төрек телендә фикер алыша. Мәҗлесләрдә бик теләп борынгы татар һәм казах халык җырларын башкарган [9, б. 14].

Ф.И. Урманчеев хезмәтләре, эпосны өйрәнүгә багышланган монографияләре басылып чыгуларыннан соң дистәләгән еллар үтсә дә үз актуальлеген югалтмаган, олы тиражларына карамастан, күптән сирәк очрый торган библиографик басмаларга әверелгән. Шуңа да 2023 ел ахырында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән галимнең «Татар халык эпосы» монографиясе, яшь буын өчен генә түгел, ә барлык фольклор белгечләре өчен дә зур бүләк булды. Китапның беренче өлешенә Ф.И. Урманчеевның «Татар халкының героик эпосы» монографиясендәге эпик дастаннар өлкәсендәге теоретик эзләнү-тикшеренүләре урын алган, халык-поэтик әсәрләренең төрле классификацияләре тәкъдим ителгән, дастан, кыйсса, эпос һ.б. терминнарның аңлатмалары бирелгән икенче бүлеге кертелә. Әлеге басманың икенче өлеше төрки халыклар өчен уртак булган «Идегәй» дастанының татар версиясен чагыштырма-тарихи һәм чагыштырма-типологик тикшерүгә багышлана. Шул ук вакытта, бу китапны әзерләү барышында үз эченә эпик әсәрләрнең, географик урыннарның атамаларын, персонажлар исемнәрен алган исемнәр күрсәткече дә төзелгән.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып һәм конференциянең фәнни-гамәли әһәмиятен күздә тотып, шуңа аерым игътибар бирәсе килә: Ф.И. Урманчеев Казан, Алабуга шәһәрләре, Татарстан өчен генә түгел, барлык дөньяга билгеле булган шәхес. Аның исеме, фәнни һәм педагогик эшчәнлеге, хезмәтләре таныштыруга мохтаҗ түгел. Ул – татар фольклористик мәктәбен яңа дәрәҗәгә күтәргән кеше, һәм олпат мөгаллимебезнең исемен онытырга һәм оныттырырга безнең хакыбыз юк. Шуңа да Казан федераль университетының Алабуга шәһәрендәге институтыннан, җирле башкарма комитеттан Фатих Ибраһим улының исемен мәңгеләштерү йөзеннән, татар һәм гомумән алганда төрки филологиясе һәм фольклористикасының актуаль мәсьәләләренә багышланган фәнни-гамәли конференция – Урманчеев укуларын – оештыруны үтенәбез. Бу – фәнни гаделлек һәм укучының укытучыга карата ихтирам билгесе буларак тарихка керерлек адым.

## Список литературы

1. Әмирхан Р.Г. Легендалар рухын тергезеп / Р.Г. Әмирхан // Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 248-251.

2. Василенко В.А. Опыт работы студенческого кружка фольклористов // Русский фольклор: материалы и исследования. V том. М.-Л.: Издательство Академии наук СССР, 1960. – С. 462.
3. Закиев М.З., Махмутов Х.Ш. Героический эпос татарского народа / М.З. Закиев, Х.Ш. Махмутов // Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 245-246.
4. Закирова И.Г. Школа Ф. Урманче в татарской фольклористике / И.Г. Закирова // Фәнни Татарстан (Научный Татарстан). 2016, № 3. – С. 140-143.
5. Мәхмүтов Х.Ш. Төрек теле аша – зур төрки дөньяга / Х.Ш. Мәхмүтов // Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 251-257.
6. Мәхмүтов Х.Ш. Халык иҗатына тугърылык / Х.Ш. Мәхмүтов // Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 231-236.
7. От редколлегии / К.М. Миннуллин, И.И. Ямалтдинов, И.Г. Закирова // Татарский народный эпос. – Казань, 2023. – С. 3-5.
8. Садыйкова А.Х. Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән / А.Х. Садыйкова // Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 257-260.
9. Светлой памяти ученого и учителя / И.Г. Закирова // Татарский народный эпос. – Казань, 2023. – С. 6-14.
10. Типология татарского фольклора. – Казань: Издательство «Мастер Лайн», 1999. – 156 с.
11. Урманчеев Ф.И. Волшебный клубок. Муса Джалиль и народное творчество / Ф.И. Урманчеев – Казань: Изд-во ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1995. – 184 с.
12. Урманчеев Ф.И. Героический эпос татарского народа. – Казань: Татарское книжное издательство, 1984. – 312 с.
13. Урманчеев Ф.И. По следам белого волка. Ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племен. – Казань: Издательство ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1994. – 125 с.
14. Урманчеев Ф.И. Татарский народный эпос / Ф.И. Урманчеев. – Казань, 2023. – 384.
15. Урманчеев Ф.И. Халык авазы. Татар халык бәетләре тарихыннан очерклар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1974. – 127 б.
16. Урманче Ф.И. Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре / Ф.И. Урманче. – Казан: Мәгариф, 2005. – 335 б.
17. Урманче Ф.И. Сибгат абый хатлары / Ф.И. Урманче // Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 238-244.
18. Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты (уку-укыту басмасы). / Ф.И. Урманче – Казан: Мәгариф, 2005. – 383 б.
19. Урманче Ф.И. Тюркский героический эпос / Ф.И. Урманче. – Казань: Издательство ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2015. – 448 с.
20. Фольклор фәнендә Урманчиев мәктәбе / Н.Ш. Хисамов // Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 3-4.
21. Хәким С.Т. Халык хәзинәләрен ачучы (Фатих Урманчеевка 50 яшь) / С.Т. Хәким // Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 237-238.
22. Ягъфәров Р.Ф. «Ак бүре» кая әйди? / Р.Ф. Ягъфәров // Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 247.